Каникуллар вакытында мо-шенникларнын алдаунын яна ысулларын уйлап табулары турында кисәтәләр.      Чираттагы яллар, каникул һәм сәяхәтләр чоры житvгә, мошенник-лар халыкнын ял, сәфәр, транспорт арендасы, остәмә акча эшләv чыганагын табу кебек мәшәкатьләренә яраклаша башлый. Эчке эшләр министрлыгы мәгълvматлары буенча, алдакчы туристлык агентлык-лары, балалар лагерьлары һәм санаторийларнын ялган сайтларын булдыра. Алар, отышлы бәядән юллама тәкъдим итеп, аванс тvләvне сорый. Акча кvчерелгәч, элемтәне озеп куя.
Аферистлар шулай ук акча эшләv тәкъдиме белән белдерvләр урнаштыра. Эшкә алабыз, дигән булып, шәхси мәгълvматлар жибәрvне, аванс кертvне сорый һәм vзләренә кирәклесен кулга тошергәч, юк була.
Шулай ук аферистлар имтиханнар тапшыру һәм вузларга керvгә бәйле алдау ысулларын да куллана. Yзләрен уку йортлары хезмәткәрләре буларак таныштырып, СМС-хәбәр аша килгән кодны яки аккаунтлар мәгълvматларын кулга тошерv очен, әйтик, имтихан нәтижәләрен тикшерvне тәкъдим итәргә момкиннәр.
Сак булыгыз: шикле сайтлар аша акча кvчермәгез, СМС-хәбәр аша килгән кодларны, парольләрне, банк карталары мәгълvматларын беркемгә дә әйтмәгез. Моннан тыш сайтларнын адресларын тикшерv, аренда сервисларынын рәсми кушымталары аша гына QR-кодтан файдалану кинәш ителә.